РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани , дом 6

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы., 6 нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» декабрь 2025 ел** **№ 16**

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлары, сайланган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы Әтнә район Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Бердәм дәүләт хакимияте системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 елдагы №25-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 №281, 14.06.2018 №481, 17.10.2018 №940, 29.12.2018 №1320, 17.11.2021 №1087, 13.12.2021 №1222, 17.09.2022 №1015, 30.04.2024 №290, 25.09.2024 №829, 25.11.2025 №994 карарлары нигезендәге үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Әтнә район Советы **карар итте:**

1. Әтнә район Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының депутатлары, сайланган вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы карарына (Әтнә район Советының 18.11.2022 №144, 27.01.2023 №167, 15.05.2024 №228, 16.11.2024 №245, 04.02.2025 №260, 25.04.2025 №275 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга;

1.2. күрсәтелгән карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2 Әлеге карарның 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш.Хисамиев

*Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 29.03.2022 елгы 120 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «12»декабрь_2025 № 16 карары редакциясендә)*
*2 нче кушымта*

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларның, контроль-хисап палатасы Рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Коэффициент<br>8 нче группа |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 44 814 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 40 334 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 40 334 |

*Татарстан Республикасы Әтнә район Советының 29.03.2022 елгы 120 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «12» декабрь 2025 № 16 карары редакциясендә)*
*3 нче кушымта*

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгының, депутатларның, авыл җирлекләрендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы Рәисенең айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаларның исемнәре | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | |
|---|---|---|
| | Унберенче группа | Уникенче группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 25 401 | 23 201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 18 254 | 16 931 |
| Депутат | 16 928 | 16 928 |
| Җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы | 16 928 | 16 928 |